Ислам нуры

اسلام نورى

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 20 (672) 22 октябрь 2018 ел (1440, Сәфәр) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

Аталар һәм балалар...

Локман Хәкимгә хикмәт бирелү тарихы гыйбрәтле. Аллаһ Раббыбыз Үзенең фәрештәләре аркылы аңа пәйгамбәрлек һәм хәлифә булуны тәкъдим итә. Локман Хәким: “Сайлау мөмкинлеге бармы?” – дип сорый. Уңай җавап алгач, икесеннән дә баш тартып: “Миңа бәлаләрдән сәламәтлек, гафият (исәнлек, саулык) кирәк. Пәйгамбәрләргә пәйгамбәрлек белән бәла килгәнен беләмен, янә хөкем кылучы олуг бәла эчендәдер. Әгәр дөрес хөкем итсә, хуш. Әмма золым кылса, урыны җәһәннәм. Миңа дөньяда түбәнлек, хурлык кылынып, ахирәттә газиз булу артыграк”, – ди. Пәйгамбәрлек һәм патшалыкка караганда гади кеше булуны артык күргәне өчен Аллаһ Раббыбыз аңа гыйлем һәм хикмәт бирә...

Локман үзенең улын Аллаһы Тәгаләне генә зурларга, бары тик Раббыбызга гына ышанырга өндәгәч, улын әти-әниләргә карата ихтирамлы булырга өйрәтә. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: “Кешегә без ата-анасына яхшылык итәргә әмер иттек, баланы анасы зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән күтәрде, ягъни корсагында авырлык белән күтәрде, авырлык белән тудырды, аның баласын имезгәнгә ике елдыр, Миңа, ата-анаңа шөкер ит, дип боердык, ахырда Миңа кайтасыз”, – ди (“Локман” сүрәсе, 14). Кеше Аллаһы Тәгаләгә шөкерана кылып, гыйбадәтләрне үтәп яшәргә, шул ук вакытта ата-анасына да зур ихтирам хисе булырга тиеш.

Локманның улы әтисеннән: “Әти, әгәр дә мин беркем дә күрмәгәндә ниндидер гөнаһ кылсам, Аллаһы Тәгалә аны ничек беләчәк?” – дип сорый.

Акыл һәм хикмәт иясе Локман Хәким улына: “И улым, әгәр кылган гөнаһың гәрчич орлыгы авырлыгында булса да, ул гөнаһың таш эчендә, яки күктә, яки җирдә булсын, Аллаһ ул гөнаһыңны кыямәт көнне алдыңа китерер. Аллаһ бик нечкә нәрсәләрдән дә хәбәрдардыр”, – ди (“Локман” сүрәсе, 16).

Олыласаң олыны...

Октябрь аеның беренче яртысында олы яшьтәгеләрне хөрмәтләү йөзеннән бик күп җирләрдә төрле эчтәлектәге чаралар уздырылды. Өлкәннәр үткәнлеге кысасында “Туфан” мәчетендә дә картларны хөрмәтләү мәҗлесе оештырылды. Әлеге чара өлкән буынга, ата-анага карата булырга тиешле хөрмәт һәм мәрхәмәтлек турында кыскача вәгазь белән башланып китте. Өлкәннәргә хаҗилар бүләге – зәм-зәм суын да авыз иттерделәр, аннары дога кылынды. Мәҗлестә алмыштан артык кеше катнашты. Мәчет имам-хатыйбы Равил хәзрәт Нуруллин өлкәннәргә бүләкләр таратты. Килгән кунаклар әлеге чара өчен бик рәхмәтле булып таралыштылар.

Нияз ГАЗИЗОВ.

БЕЛДЕРҮ

Чаллы мөхтәсибәте һәм “Әбүзәр” мәчете имам-хатыйбы Али хәзрәт Баһаветдинов ярдәме белән 2 нче һәм 4 нче ноябрьдә кичке сәгать җидедә күп балалы, мохтаҗ һәм гади мөселман гаиләләре өчен Чаллы дельфинариенда шоу оештырылачак. Дельфиннар чыгышын карау 400 сум, 3 яшькә кадәр балалар өчен керү бушлай.Теләүчеләр билет алу өчен алдан ук языла ала.

ТР МДН хәбәр итә

Татарстан Республикасы Президенты җитәкчелегендәге сәфәр кысаларында Камил хәзрәт Сәмигуллин Мисыр Гарәп Республикасында булды. Каһирәдә хәзрәт Мисыр премьер-министры М.Мадбули, шулай ук дөньядагы иң борынгы университетларның берсе “Әл-Әзһәр” җитәкчелеге белән рәсми очрашуларда катнашты. Мәшһүр дини университетта студентларны укытуны оештыру мәсьәләләре һәм Болгар ислам академиясе белән хезмәттәшлек мөмкинлеге турында сүз барды.

***

Хәтер көне уңаеннан Казан Кремле буенда шәһитләрне искә алу чарасы үтте. Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин 1552 елда – Казан алынганда шәһит китүчеләрне, сугышларда һәлак булучыларны искә алып, алар рухына, Аллаһы Тәгаләдән оҗмах теләп, дога кылды. Чарада ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы әгъзалары катнашты.

***

Казанның Галиев мәчетендә мөселман яшьләре фикер алышу клубының яңа сезонда беренче очрашуы узды. Очрашу “Дини һәм дөнья тормышы” темасына багышланды. “Без дөньяви дәүләттә яшибез. Еш кына хәзерге җәмгыятьтә дөнья тормышы динилеккә каршы куела. Фани дөнья һәм ахирәт – нинди чикләр бар, иң мөһиме – ничек шәригать кануннарын бозмаска һәм динеңне югалтмаска?” Әлеге һәм башка сораулар дөньяви дәүләттә яшәүче дини кешеләрдә барлыкка килә – мөселман яшьләре шул хакта фикер алышты.

НАМАЗ

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: “Аллаһыга мөрәҗәгать итеп, һәрвакыт Аңа итагатьтә булыгыз, һәм Аңа гөнаһлы булудан сакланыгыз, билгеләнгән намазларыгызны вакытында укыгыз, һәм һичнәрсәне Аллаһыга тиң кылмагыз, мөшрикләрдән булмагыз”, – ди. (“Рум” сүрәсе, 31 аять).

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вәсәлләм: “Намаз – диннең терәге. Намаз кылмаган кеше – динне җимерүче”, – дигән.

Ошбу хәдистән аңлашылганча, нигезсез йорт була алмаган кебек, намазсыз Ислам да, мөселманлык та була алмый. Намаз уку һәр мөселманның бәхетле булуы һәм дә үз мәнфәгате өчен кирәк. Үзләрен мөселман дип, шул ук вакытта намаз укырга вакытым юк дип йөрүчеләр, ислам динен торгызу урынына, ислам динен җимерүчеләр булалар.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: “Мин кешеләрне дә, җеннәрне дә Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен яралттым”, – ди.

Намаз – гыйбадәтнең иң олысы. Адәм баласы яралтылганнан соң сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вәсәлләм шәригатендә гыйбадәт кылу гыйлемнәрен алып, көненә биш тапкыр намаз уку вазыйфасы йөкләтелгән. Һәм бу үзен мөәмин-мөселман диеп йөргән кеше өчен, Аллаһы Тәгаләнең биргән нигъмәтләренә шөкер кылып, Аның рәхмәте белән йөкләнгән хөрмәтле вазыйфа булып тора. Иман китергәннән соң намаз – гыйбадәтләрнең башы һәм иң изгесе. Намазның әҗере-саваплары, файдалары санап бетергесез. Шуларның берсе турында пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вәсәлләм: “Намаз – мөәминнәрнең мигъраҗы”, – ди.

Мигъраҗ – бөекләр янына күтәрелү. Ягъни, без намаз укыганда Аллаһы Сүбхәнә вә Тәгалә каршына басып, Аның колы икәнлегебезне танып- дәлиллибез.

Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вәсәлләм намаз турында: “Намаз – мөәминнең нуры ул. Мөселманның өйдә кылган намазы өен нурландырыр”, – ди.

Хәдистә: “Өйләрегезне намаз кылып, Коръән укып нурландырыгыз”, – диелә. Ягъни, фарыз намазларны мәчеттә укып, нәфел намазларын өегездә укып, өйләрегезне нурландырыгыз. Елына бер тапкыр азан әйтеп, йә булмаса берәр бабай чакырып, аннан азан әйттереп кенә өйләрегез нурланмый, ә намаз укып нурлана.

Икенче бер хәдистә: “Аллаһның Үзен күргән кебек гыйбадәт кыл”, – диелә. Ягъни, Раббыңа гыйбадәт кылганда, намаз укыганда, Аны күргән кебек ихлас күңел белән, күңел рәхәтлеге тоеп, барлык чит булган нәрсәләрне онытып гыйбадәт кылу өстеңә йөкләнгән коллык бурычларны җиренә җиткереп үтәүне аңлата. Шул вакытта намазның тәмен белергә була. Күзләребез белән Раббыбызны күрмәсәк тә, ул безне күрә, барлык уй-фикерләребезне дә белеп тора. Без бит мәчеткә гыйбадәт кылырга килгәндә, Аллаһы Тәгаләнең: “Үзеңә үлем килгәнчегә кадәр Раббыңа гыйбадәт кыл”, – дигән әмерен истә тотып киләбез. Ошбу әмерне мәчеткә килгәндә генә түгел, башка вакытларда да онытмасак иде.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вәсәлләм: “Гамәлләрегезнең иң фазыйләтлесе, эшләрегезнең иң хәерлесе – намаз уку”, – диде.

Икенче хәдистә: “Намаз – һәр хәернең ачкычы. Намаз – җәннәтнең ачкычы”, – диелә. Ошбу хәдисләрдә иң хәерле эш, иман китергәннән соң намаз уку, диелә. Иман – ышану беренче дәрәҗәдә, ә намаз икенче дәрәҗәдә. Чөнки иман китермичә, ышанмыйча намаз укып булмый бит.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: “Мине белер һәм аңлар өчен намаз кыл”, – ди. Кеше кемне яки нәрсәне яратса, шуны хәтерендә даими сакларга, һәрвакыт аны аңларга, аның турында күбрәк белергә тырыша. Кешенең фикерендә-уенда нәрсә булса, аның зикере дә, сүзе дә шуның турыда гына була. Аллаһы Тәгаләне барча мәхлуклардан да күбрәк яратучы Раббысы турында күбрәк уйлап, Аның әмерләрен үтәргә тырышып, намазын вакытында укый да җәннәтле була. Ә инде акчаны, малны күбрәк яратучы шул малга, акчага табына. Миңа күбрәк булсын дип, башкалардан зуррак, дәрәҗәле урында булырга тырышып, ахыр чиктә шайтанга гыйбадәт кыла башлый. Һәм шуның белән ширек кылганын сизми дә кала. Кыямәт көнендә җәһәннәмгә олага.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вәсәлләм: “Аның өчен фәрештәләрнең ничек итеп дога кылганын күрсә, ул кеше намаздан һич аерыла алмас иде”, – ди. Без өйдән мәчеткә намаз укырга диеп чыгып киткәннән өйгә кайтып кергәнгә кадәр вакытларыбыз намаздан санала. Фәрештәләр шул вакыт эчендә аның өчен догада булалар.

Вәгазь башындагы аятькә яңадан әйләнеп кайтсак, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: “Аллаһыга мөрәҗәгать итеп, һәрвакыт Аңа итагатьтә булыгыз, һәм Аңа гөнаһлы булудан сакланыгыз, билгеләнгән намазларыгызны вакытында укыгыз, һәм һичнәрсәне Аллаһыга тиң кылмагыз, мөшрикләрдән булмагыз”, – ди. (“Рум” сүрәсе, 31 аять).

Мөселман кардәшләрем! Ошбу аятьнең һәрбер сүзен калебебез аша үткәреп, Раббыбызның безгә әйткәненә төшенсәк иде.

Аллаһы Тәгалә: “Дөреслектә, хак мөәминнәр газаптан котылып мәңгелек сәгадәткә (бәхеткә, уңышка) ирештеләр. Алар намазларын хошугъ (түбәнчелек) әдәп белән, Аллаһыдан курку белән укыйлар”, – дип әйтә. (“Мөәминнәр сүрәсе; 1,2 аятьләр).

Риваятьтә: Пәйгамбәребез салләллаһү галәйһи вәсәлләм, намаз укыганда, башта күзләрен күк тарафына юнәлтеп укыган. Ошбу аять иңгәннән соң, намазда сәҗдә урынына карап укый башлаган. Гомумән, намаз укучы намаз урынына карап укырга тиеш. Намазда хошугъ кирәк, шул намаз укучы кеше уң һәм сул якларында кем торганны белмәсен. Кайберәүләр янәшәсендә кемнәр басып торуын гына түгел, үзеннән соң артта өченче сафта торучының намаз укыганда җибәргән кимчелекләрен дә әйтеп бирә ала. Бу да булдымы җәмәгать белән намаз уку?

Шулай итеп, Аллаһ уңышка ирешүнең төп шарты итеп Аллаһ каршында түбәнчелекле булуны билгели.

Пәйгамбәребез салләллаһү галәйһи вәсәлләм әйткән: “Фарыз намазы вакыты җиткәч, тиешенчә тәһарәт алучы, ә намаз вакытында тиешле түбәнчелек күрсәтүче һәм барлык сәждәләрне тиешенчә үтәүче һәрбер мөселманга, зур гөнаһлар кылмаган булса, бу намазы һичшиксез аңа кадәр кылган гөнаһларын юу булачак. Бу һәрвакытта да шулай калачак”.

Бервакыт Пәйгамбәр Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вәсәлләмнән: “Гамәлләрнең кайсы иң яхшы санала?” – дип сораганнар. Ул әйткән: “Намазны үз вакытында укы”.

Гобәдә бине Сәмит Пәйгамбәр салләллаһү галәйһи вәсәлләмнең түбәндәге сүзләрен ишеткән: “Аллаһ биш вакыт намазны фарыз кылган. Алар алдыннан тиешенчә тәһарәт алучы һәм аларны билгеле бер вакытта, рөкүгъ, сәждәләрен камил рәвештә үтәп, тиешле тыйнаклык күрсәтеп укучы Аллаһының “үзен гафу итәм” дигән вәгъдәсенә өметләнергә хокуклы. Ә моны эшләмәүчеләргә Аллаһының вәгъдәсе кагылмый. Әгәр дә Ул теләсә – аны гафу итәчәк, теләсә – газаплаячак”.

Намазын вакытында укучы кеше Раббысы Аллаһка буйсынган хәлдә, гөнаһлардан сакланып, Аллаһка ширек кылудан тыелып яшәүче була. Ә инде өсләре бөтен, өйләре һәм урыннары җылы, тәннәре сәламәт була торып фарыз намазларын калдыручы һәм моның өчен күңелләре борчылмаучы кешенең күңеле соңгы чиккә кадәр җитеп каралуына бер мисал булып тора. Бала-чагалары, өй җәмәгате каршында Ислам дине терәге булган намазны укымаучы ир кеше шул балаларыннан хәерле эшләр өмет итә ала микән? Гаилә башлыгы булган ир кеше намазларны үзе укырга һәм динне гаиләсенә дә өйрәтергә бурычлы ителгән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вәсәлләм: “Намаз минем өчен шатлык һәм күз нуры”, – дигән.

Намаз укучы кеше Раббысы белән бәйләнешкә кергәнгә күрә, намаз тәкъва мөселман өчен күз нуры гына түгел, тынычлык табу чарасы да булып тора. Хәдистә: “Мөәмин белән кәферне аера торган нәрсә – ул намаз”, – диелә. Әмма башка кешегә: “Син – кәфер, чөнки син намаз укымыйсың”, – дип әйтергә хакыбыз юк. Бу сүзләрне һәр кеше үзе генә аңларга, белергә тиеш: ул кәферләр беләнме, яисә мөәминнәр беләнме. Ә инде Кыямәт көнендә кемнең кем икәнлеген Аллаһы Тәгалә билгели.

Раббым Аллаһ, өстебезгә йөкләгән намазларны үземә, гаиләмә, нәселемә һәм дә мөәмин-мөселман кардәшләремә кимчелек-хатасыз үтәп, Үзеңнең ризалыгыңа ирешергә, рәхмәтең белән Җәннәтеңә керергә насыйп әйләсәң иде. Әмин!

Равил хәзрәт Нуруллин,
Чаллының “Туфан” мәчете имам-хатыйбы.

МИНЕМ ФИКЕР

***Рәис хәзрәт Әхмәтов**, Чаллының “Сөембикә” мәчете имам-хатыйбы:*

Кеше теле белән яхшы сүзләр дә, гөнаһлы сүзләр дә сөйләргә мөмкин. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.): “Кем дә кем миңа авызы арасындагы (телен) һәм ике аягы арасындагы (җенес) әгъзасын сакларга вәгъдә итсә, мин аңа җәннәт вәгъдә итәм”, – дигән хәдисе дә бар бит. Артык күп сөйләшкәндә, кеше хакына керү куркынычы бар. Бервакыт Пәйгамбәребез (с.г.в.) сәхәбәләре белән утырганда, шундый сорау бирә: “Мөфлис кем ул?” – ди. Үзе үк җавабын да әйтә: “Мөфлис – ахирәткә күчкәнче укыган намазы, биргән сәдакалары да булыр. Әмма дөньялыкта чагында кеше сүккән, кеше сөйләгән булу сәбәпле, Аллаһы Тәгалә ахирәттә аның бар изгелек-савапларын алып, ул рәнҗеткән кешегә калдырыр”. Безнеңчә гап-гади итеп әйткәндә, банкротка чыгып, бернинди байлыгы калмаган кеше хәлендә була инде.

Бервакыт Әбү Хәнифә янына бер кол килә: “Вәгазьләреңдә бер кол азат итүнең фазыйләтләре турында сөйлә әле. Шуны тыңлап, хуҗам мине азат итмәс микән?” – дип үтенә.

Бер җомгада килә кол әлеге вәгазьне ишетергә өметләнеп, икенче, өченче җомгада... Дүртенче җомга вәгазендә генә ишетә дә аптырап сорый: “Мин синнән дүрт атна элек сораган идем бу хакта, ни өчен бүген генә укырга булдың?” – ди бу.

“Беләсеңме, синең үтенечеңнән соң мин кол сатып алдым. Аны азат иттем. Менә, үзем гамәл кылгач кына шул хакта сөйләдем”, – дип җаваплый Әбү Хәнифә.

Без еш кына кеше хакында, аның гамәлләре хакында тегесен-монысын сөйлибез, тел тик тормый бит. Сөйлибез дә онытабыз. Ә бит сөйләгәннәр барыбер безнең өстә кала. Без аның өчен ахирәттә җавап бирергә тиеш булабыз! Янә Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисен искә төшерик: “Сөйләсәгез, кеше хакында хәерле нәрсәләр генә сөйләгез, хәерле гамәлләрен сөйли алмасагыз, тик торыгыз!”...

Колак салсаң, үкенмәссең

* Бер-берегезне гайбәт кылмагыз! Үлгән кардәшегезнең итен ашарга яратыр идегезме? Әлбәттә, яратмас идегез

* Кеше үзе юкта аңа зыян китерерлек нәрсә сөйләү ул гайбәт була

* Үзегездән түбән булганнарга карагыз, бу Аллаһының нигъмәтләрен кимсетмәскә ярдәм итә

* Үзенә теләгәнне кардәшенә теләмичә, берегез дә чын иманлы булмассыз

* Бер кешегә карата нәрсәдер кылырга теләгән кеше шул эшне иң элек үзенә үлчәп карасын. Әгәр үзе яратырлык булса, кешегә карата да кылсын, әгәр дә үзе яратмаслык булса, кешегә карата да яраклы күрмәсен.

БЕЛӘСЕЗМЕ?

Ифтира – кешене урынсызга гаепләү, ялган сүзләр белән кешенең дәрәҗәсен төшерү, һич булмаган нәрсәләр сөйләп, халык алдында кешенең исемен пычрату.

Ифтира, ягъни яла ягу Ислам динендә хәрамнардан санала, чөнки ифтира мәгъсум (гөнаһсыз) кешеләрне авыр хәлдә калдыра. Кем турында булса да сөйләгәндә, ул сүзләрнең иясенә барып ирешүе турында да уйларга кирәк. Халыкның “тел пычактан үткендер” һәм “пычак ярасы төзәлер, тел ярасы төзәлмәс” дип әйтүе дә юкка түгелер.

Тел белән эшләнгән гөнаһларның берсе – яла ягу. Әгәр дә теленә хуҗа була белмәсәң, бу бик күп бәлагөнаһларга сәбәп булырга мөмкин. Бу нисбәттә ислам галимнәренең түбәндәге кисәтүләрен искә төшереп китү урынлы булыр: “Ашаган вакытта авызга кабасы нәрсәгезгә дикъкать иткән, зарарлы вә начар нәрсәләрне ашамаска тырышкан кебек, авыздан чыккан сүзләргә дә дикъкать итеп, сүзләребез белән башкаларга зарар итмәү – әхлакый вазыйфаларыбыздандыр”.

Динле һәм динсез

Бүген дингә килүчеләребезнең байтагының тизрәк күбрәк савап эшлисе килә. Бу – табигый да. Чөнки күпме гомеребез намазсыз, хәрамнардан тыелмыйча заяга үткән. Күпме гомеребез калгандыр – белмибез. Шуңа күрә әүвәлге гөнаһларыбызга да кәффәрат булырлык (арынырлык) изгелекләр эшлисе килә.

Гөнаһлардан тыелып, нәфесеңне җиңеп яши алуның ләззәтен дини кеше генә аңлый. Динсезгә аны күпме генә төшендерсәң дә аңлый алмый. Бүген мәчетләрнең буш торуының да бер сәбәбе шул. Динсез кеше мәчеттә намаз укуның тәмен тоя алмый. Андый кешене мәчеткә намазга чакыру, аның савабын аңлату сукырга – табигать матурлыгын, чукракка кош сайравының гүзәллеген төшендергән кебегрәк.

Җәлил хәзрәт Фазлыев,
Татарстанның баш казые.

Уңышка ирешү сере

(Хикәя)

Искәндәр абый өстәл янына утырып, тәмләп кенә чәй эчәргә җыенган мәлдә, ишегалдында күрше егете Рөстәмнең хәвефле тавышы ишетелде:

– Абый! Абый! Чык әле тизрәк, абый! Харап булды бит, ә, харап булды-ы!..

Теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалып, Искәндәр абый аш бүлмәсенең ачык тәрәзәсеннән башын чыгарды да, чәеннән бүлдергән күршесенә ачулы караш ташлап, канәгатьсез мыгырдап куйды:

– Йә, нәрсә булды тагын?

Кабаланып йөгергәннән тыны беткән егет нәкъ тәрәзә каршысында туктап тирән сулыш алды да, кулы белән урам якка ишарәләп, коты чыккан кыяфәттә бер киртәгә, бер күрше абыйсына текәлеп:

– Анда... коеда... анда сезнең кәҗәгез коега егылып төшкән, Искәндәр абый! – диде.

– Вәйт сиңа мә! – дип әллә ни исе китмәгәндәй сөйләнеп куйган абзыйның хатыны Рауза апа шомлы хәбәрне ишетүгә илерә үк башлады:

– Үлә-әм! Кайсысы-ы? Исәнме-е?!

Аннары тәрәзә янында аптырашлы халәттә басып торган иренә дәште:

– Күр әле моны, ә? Ник басып торасың!? Әллә йөрәгең дә җонланганмы?! Йөгер әйдә тизрәк!

Әмма Искәндәр абый бернинди хисемоцияне чагылдырмаган кызыл йөзен хатынына таба борып, кыска гына ике җөмлә әйтү белән чикләнде:

– Син, әйдә, кысылма! Юкса, кысылып калуың бар...

Язмыш шаяруы дигәндәй, Искәндәр абыйларның кәҗәсе мал табибы Фәнзилнең капка алдындагы иске коесына егылып төшә. Ишегалларында яңа кое казытканнан соң, урамдагысы ташландык хәлгә килгән була. Ни чылбыры, хәтта куласасы да булмаган шул иске коены күргәч, Искәндәр абый “хым” дип кенә әйтеп куя да уйга чума.

– Нишләтәсең инде аны хәзер? – диде ветеринар, кулларын як-якка җәеп. – Кәҗә бит ул болан кебек нәзек һәм бик куркак хайван, инде егылып төшкәнче үк җан биргәндер...

Әмма кое төбеннән кызганыч тавышлы “Мә-ә-ә!” дигән аваз ишетелгәч, җыелган күрше-күлән моның болай түгеллегенә инанды. Ветврач исә институтта алган белемнәрен “җигеп”, үз сүзендә торуын дәвам итте:

– Моның кадәр биеклектән егылып төшкән малның рәте калмый инде аның! Имгәнгәндер, аяклары сынгандыр... Кыскасы... Миңа бу кое барыбер кирәкми: кәҗәсе-ние белән бергә күмеп куйыйк та – шуның белән вәссәләм!

Шушы гадәти булмаган тәкъдимне ишеткәч, кәҗә хуҗасы беравык нәрсә әйтергә белмичә аптырап басып торды: әүвәл бимазаланудан хафага калган карчыгы Раузаны исенә төшереп, кәҗәне ничек тә чыгарасы иде дип уйлап куйса, соңыннан малкайны интектереп, аны чиләнеп чыгарганны күз алдына китергәч, Фәнзил фикере ничектер дөресрәк тоела башлады. Ә инде табиб: “Гаеп миндә дә бар – ыстрахуфканың бер өлешен бирермен” дип вәгъдә иткәч, Искәндәр абый аның белән ризалашмыйча булмас дигән катгый нәтиҗәгә килде.

Килешенде – бетте-китте: янәшәдәге чүп үләне каплаган иске балчык өемен актарып, Рөстәм белән Фәнзил ике көрәкләп коены күмә башлагач, нечкә күңеллеләр “аһ” итте.

– Ужжыыс... – диеште кызлар, күзләрен түгәрәкләп һәм авызларын кул белән каплап. Әмма хәлнең бик киеренке булуына карамастан, чагыштырмача тыныч торган адәмнәрдән аермалы буларак, өстәгеләр нәрсә эшли башлаганын абайлаган кәҗә ачыргаланып акырырга тотынды. Аның “Мә-ә-ә!” дигән авазы бу мизгелдә күпләргә “Күм-мәәә!!! Күм-мәәә!!!” дип ишетелде. Ләкин нишләмәк кирәк – мәсьәлә хәл ителгән: күмәсе тәк күмәсе.

Озак вакыт узмый – бахыр малкай кычкырудан туктый, дөнья тынычланып киткәндәй була. Бераздан Рөстәм белән Фәнзилгә катырак бәгырьле күрше егетләре дә ярдәмгә килгәч, эш тизләтелә, ә инде коеның яртысыннан күбрәге күмелгәч, Фәнзил, эшне туктатып, башын аска иеп эчкә карап ала да... нәрсәгәдер бик шаккатып, гаҗәпләнүеннән сызгырып куя. Шуннан соң башкалар да кызыксынып аска карый, һәм коега атылган балчык өстендә аягында басып торган канәгать кыяфәтле исән-имин кәҗәне күргәч, үзләре дә сизмәстән шулай ук сызгырып җибәрәләр.

– Вәйт иты да-а! – дип гаҗәпсенеп әйтеп куя хәйран калган Искәндәр абый.

Хәлнең хикмәте нәрсәдә булуын аңлап алган егетләр коега тагын берничә көрәк балчык ата, кәҗә исә өстенә атылган балчыкны селкеп төшерә дә, аяклары белән тәйгечләп, тыгызлап куя. Моны күргән авыл агай-энеләре түзми һәм “Сүбехәәнәллаһ - мәә шәәллаһ!” – дип тел шартлатып, коега балчык атуларын дәвам итә. Кәҗә дә тырышып үз эшен башкара. Шулай итеп, озак вакыт та үтми, кое ахырына кадәр күмелеп килгәндә, Искәндәр абыйларның газиз малкайлары өскә чыга. Янәшәдәге тактага сикереп төшкән кәҗәне авыл халкы кул чабып каршы ала.

Шушы искитәрлек кызык вакыйга күпләр өчен зур гыйбрәт була. Авыл имамы Җомга намазында бу хәлне искә төшереп, шундый аңлатма бирә:

– Һәр кешенең тормышында проблемалар булмыйча калмый. Авырлыклар, бәла-казалар рәвешендәге “балчык” өстебезгә гел коелып тора. Әмма шуны аңлау мөһим: безгә килгән һәр авырлык ул – уңышка ирешү өчен бер адым, чөнки шушы авырлыкларны “селкеп төшерү” нәтиҗәсендә этәрелеп алга таба кузгалып китәр өчен үзенчәлекле бер “мәйданчык” барлыкка килә.Тормыш юлыннан атлаганда һәркем Фәнзилнең коесы кебек тирән караңгы чокырга да егылып төшәргә мөмкин. Шул вакытта өстебезгә коелган, бик куркыныч тоелган кыенлыклар “балчыгын” өстән каккалап, тыгызлап куярга һәм шулай итеп, әкрен генә булса да өскә күтәрелергә кирәк. Искәндәрләрнең кәҗәсе нәкъ шулай эшләп, сезгә бик яхшы сабак биргәнен онытасы түгел, җәмәгать, онытасы түгел...

Ришат Курамшин,
Кукмара мәдрәсәсе мөдире.

Безгә язалар

Кичер, Раббым!..

Әссәламугаләйкум, дин мөбиндә газиз кардәшләребез! Сезгә сәламәтлек, эшегездә уңышлар, ике дөнья бәхете телим. “Ислам нуры” газетасына рәхмәтебез бик зур, безнең барлык сорауларыбызга да җавап яздыгыз. Мәчеттә бергәләп укыдык, аңладык, дөрес эшләмәгән җиребезне дөресләргә ният иттек. Хатка өстәп, бер шигыремне дә җибәрәм.

Зәлифә Газизянова,
Уфа районы, Николаевка авылы.

Авылыма кайттым, сагындырган.
Таныш сукмаклардан атладым.
Туганнарны күреп шатландым,
Күршеләрне генә тапмадым.
Зират, салкын тынлык. Шыбырдашып,
Агачлары гына серләшә.
“Син үзең дә монда киләсең”, – дип,
Минем турыдамы сөйләшә?
Күпме кеше ята җир астында,
Күпме ташлар алар өстендә.
Монда минем газиз әнкәм ята,
Чардуганы инде искергән.
Ә бу минем күршем. Бергә үстек,
Бергә йөрдек күпме юлларда.
Алабута, кузгалаклар җыеп
Кайта идек ачлык елларда.
Вакытлымы, әллә вакытсызмы,
Гомерегез инде өзелгән.
Туфрактан юрганнар ябылган,
Өстегездә ташлар тезелгән.
Ясин укыйм барыгыз өчен дә,
Рухыгыз сезнең шат булсын.
Яткан җирегез гыйззәт ястыклары булып,
Җәннәтләргә ишек ачылсын.
Күп гамәлләр кыла алыр идек,
Гомер шулай бик шәп акмаса.
Кичер мине, Раббым, иртәгәсен
Минем өчен таңнар атмаса...

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

“Гыйбадәт кылуның тәме бар”

«Намазда булган бер гаилә белән танышырга туры килде. Сүз арасында алар намазны көн дә укымауларын әйтте. Аллаһы Тәгалә каршында ихлас булу өчен, күңел кушканда гына укыйлар икән. Имештер, намазың «укыдыммы укыдым» кебек булмый, ә чын күңелдән килеп чыга... Шушы хакта сезнең газета аша берәр хәзрәттән үтемле җавап ишетәсем килә», – дип язган безгә бер газета укучыбыз. Без әлеге хатны «Кабан арты» мәчете имам-хатыйбы Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИНга юлладык.

– Намаз ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан безгә йөкләтелгән гыйбадәт һәм аның күләме, тәртибе, рәкәгатьләр саны, догазекерләре – барысы да Аллаһыдан, аларны беркем дә үз теләге һәм ирке белән үзгәртә, нәрсәдер өсти дә, киметә дә алмый. Намаз гыйбадәтен беренче булып Мөхәммәд Пәйгамбәр алып килмәде, ул атабыз Адәмнән дәвам итә. Җир өстенә пәйгамбәрләрнең берсе дә намазсыз килмәде. Шунысын әйтергә кирәк: әлеге бөек әмер югала башлагач, Аллаһы Тәгалә ахыр пәйгамбәренә бөтен кешелекне биш намазга чакырырга боера. Билгеле булганча, Аллаһ илле вакыт намаз укырга куша. Әмма пәйгамбәребез: «Илле намаз өммәтемә бик авыр булыр», – дигәч, аның шәфәгате белән биш намаз булып кала. Ләкин намазның күләме ун мәртәбәгә кимесә дә, әҗер-савабы шул ук була. Нәтиҗәдә биш намазын укыган илле намаз савабына ирешә. Шуңа күрә, намазның күләме биш. Ул өч тә, дүрт тә, алты да була алмый. Хәтта күбрәк укырга теләгән кеше дә биштән артыгын башкара алмый, бу дингә үзгәреш-яңалык кертү була. Намаз фарыз кылынганнан соң, Аллаһы Тәгалә пәйгамбәренә намаз уку тәртибен һәм вакытларын өйрәтү өчен остаз итеп Җәбраил фәрештәне җибәрә. Күкләрдән иңгән мөгаллим ике тәүлек буена пәйгамбәребезгә имам булып тора. Беренче көнне ул намазларның кергән вакытларында, икенче көнне чыккан вакытларында килә. Ахыргы намазны укыганнан соң ул пәйгамбәргә борыла һәм: «Әй, Мөхәммәд, бу сиңа кадәр яшәгән пәйгамбәрләрнең намаз вакытлары. Вакыт шушы ике вакыт арасында булыр», – дип әйтә (Ибн Габбәстән килгән хәдис). Аллаһының динендә һәр гыйбадәт, аның тәртибе, рәвеше Аллаһыдан килгән әмергә нигезләнергә тиеш. Әгәр Аллаһ дине кеше акылына, аның хисләренә нигезләнә торган булса, бу Аллаһ дине түгел, нәфес-мин дине була.

– Гыйбадәтне күңел таләбенә генә бәйләп калдырырга ярамый, анысы аңлашыла. Әмма намазның сыйфаты хушугъ («тынычлану», «түбәнчелек күрсәтү») халәтенә бәйле бит?..

– Әлбәттә, шайтан кешене вәсвәсәсез калдырмый. Адәм баласы еш кына дөнья куып, эш-гаилә мәшәкатенә чумып, Аллаһыны оныта башлый, күңеле каралып китә. Менә намазның бер вазыйфасы – кеше белән Аллаһ арасын бәйләп тору. Намазлыкка баскан кеше үзенең Раббысын исенә төшерә, асыл кыйбласына кайта. Биш вакыт намазның тәүлек буена сузылуының хикмәте дә шундадыр. Һәр намазның вакыты Бөек Раббы тарафыннан билгеләнгән һәм кешенең нәкъ шул вакытларда дөньядан биш-ун минутка булса да өзелеп торуы, тәгәрмәч эчендәге тиен сымак чабудан туктап хәл алуы мөһим. Әби-бабайларыбыз намаз укуны тыйган чорларда да иманнарына тугры калдылар, биш вакыт намазларын ташламадылар. Сугыш елларында да бичара әбиләребез, ирем сугышта, балаларым ач, күңелем тартмый яки кушмый дип намаз укымый тормаган.

Ә күңелгә килгәндә, намазны күңеленне биреп уку ансат эш түгел, моның өчен күп тырышлык куярга, калебеңне пакьләргә кирәк. Күп кенә намаз укучыларның хаталары шунда: алар намаз уку тәртибен өйрәнә, догаларны ятлый да, шуның белән намаз темасын өйрәнүне ташлый. Әлеге олуг гыйбадәтне «Намаз уку тәртибе» дигән китапчык белән генә өйрәнү мөмкин түгел. Ислам дөньясында намаз турында бик күп китаплар, зур-зур хезмәтләр язылган. Кызганыч, намаз укучыларның күпчелеге намазда нәрсә эшләгәннәрен һәм нәрсә әйткәннәрен аңламыйлар. Мәсәлән, намазда күз карашын сәҗдә урынына төшерү тәртибе бар. Күпләр аны китапта язылганга гына шулай эшлиләр. Аның мәгънәсе исә – кеше намазында Кем каршына басуын аңлап, Аның галәмнәр хуҗасы, Бөек кодрәт иясе икәнен белеп, шул ук вакытта үзенең бик зәгыйфь зат булуын һәм күпсанлы хаталарын танып, күзләре аска төшә. Ни өчен пәйгамбәрнең сәхәбәләре алдан ук кайгырып, чиста киемнәрен киеп намаз вакытын көткәннәр? Алар кем каршына килеп басуларын яхшы аңлаганнар. Намазыңны аңлап укысаң, аның тәме дә башка була, мәшәкате дә юкка чыга. Әле кайчан гына өйләдә Раббым белән серләшкән идем, хәзер икенде намазы җитеп, янә Аңа якынаю рәхәтен татыйм, дип сагынып көтә. Авыру кешенең авызы ризыкның тәмен татый алмаган кебек, рухи авырулар белән агуланган йөрәк тә гыйбадәтнең тәмен тоя алмый тилмерә. Әмма кеше изгелек кылуыннан туктамый, чөнки изгелек кылган саен, күңел төзәлә. Күңел савыккан саен, аның тәмен күбрәк тоя.

– Биш вакыт намазны кич белән җыеп укучылар үзләрен аны бөтенләй укымауга караганда яхшырак дип аклый. Намаз укымаучылар арасында аракы эчмим, кеше рәнҗетмим, иң мөһиме - мин Аллаһка ышанам дип әйтүчеләр дә бар. Аллаһ каршында алар бертөсле буламы?

– Намазның бөтен хикмәте үз вакытында башкарылуында. Әгәр табиб авыруга тәүлегенә биш мәртәбә берәр сәдәф дару эчәргә кушып, төгәл итеп вакытларын билгеләсә, ә авыру моңа җиңел карап, кичен барысын да учка җыеп авызга тутырганнан дәва булырмы икән? Аллаһы Тәгалә беркайчан да бәндәсенә күтәрә алмаслык йөк тапшырмый. Әллә нинди мәшәкатьле эшләрдә эшләп тә, намаз укырга җаен табарга була, теләк һәм Раббыңа карата ныклы мәхәббәт кирәк. Басып укый алмасаң, утырып укы, утырып та укырга кодрәтең җитмәсә, яткан җирдән укы, тәһарәт алырга суың булмаса, тәяммүм алып укы дигән. Әмма бер җирендә дә, укымасаң да була, димәгән. Кайберәүләр, Аллаһы Тәгалә безне көн саен биш намаз укытып интектерәсе киләдер инде, дип уйлый. Аллаһыга власть җитә, ул синең намазыңа, синең үзеңә дә мохтаҗ түгел. Без намаз укыганнан Аллаһының акчасы да, көче дә артмаган кебек, без намаз укымаганнан да Аның дәрәҗәсе кимеми. Намаз ул – безгә Раббыбыз тарафыннан бүләк итеп бирелгән нигъмәт. Кайбер авыл башлыгына да приемга эләгү өчен атна буе йөрергә кирәк. Галәмнәр Раббысы безгә көненә биш мәртәбә Аның каршына килеп, Аның белән сөйләшергә, Аннан ярдәм сорарга мөмкинлек бирә. Моның өчен ерак юллар үтәргә дә, алдан язылып, төрле сакчылар аша үтәргә дә кирәкми. Намаз безнең диндарлыгыбызны саклый, күңелебезгә ял, тәнгә сихәт, ризыкка бәрәкәт бирә. Пәйгамбәребез дә, намаз күземнең карасы, күңелемнең шатлыгы булды, дигән. Ә бөтенләй мәшәкатьсез булмый инде. Ике рәхәт бергә килми. Аруны белмәгән рәхәтнең ләззәтен татымас. Аллаһ өчен бераз мәшәкатьләнмичә дә булмый. Ул безнең өчен көн саен таңын арттыра, болытларга төяп, яңгырын китереп яудыра. Ул биргән ризыкларны ашыйбыз, Аның суларын эчәбез, Аның һавасын сулыйбыз. Күзләрең күрә, аягың йөри, колагың ишетә – нишләп әле Аңа рәхмәт әйтеп намаз укымаска?!

– Намаз уку - җаваплы гыйбадәт, гөнаһ кылудан туктыйсы була дип, укый башларга икеләнеп торучылар да юк түгел...

– Намазның кеше тормышын үзгәртүдә бик зур йогынтысы бар. Әгәр кеше намазын чын күңеленнән укыса, намазы аның күңелен тазартып, ул гөнаһлардан үзе китәчәк. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә: «Намаз кешене явыз һәм бозык эшләрдән тыя», – дип әйтә. Пәйгамбәребезгә бер кеше килә дә, мин бер кешене беләм, ул үзе урлый, үзе намаз укый, ди. Пәйгамбәр, намаз укымасын, димәде, намазында ихлас булса, тиздән намазы урлашудан туктатыр, диде. Әгәр бер кеше «мин биш намазымны укыйм» дип күкрәк кагып, аннан урлашып, аракы эчеп яки зина кылып йөрсә, димәк, ул кешенең намазын укуында шик бар. Бервакыт, мәчет юлына басып килүче бер кеше килеп: «Хәзрәт, аракы да эчмим, сөяркәләремне дә ташлап бетердем, берсе генә калды. Анысын ташларга көчем җитми», – дигәч, аңа: «Син, абый, намаз укый башла әле», – дип әйткән идем. Ул миңа, гаҗәпләнеп: «Ничек инде, көндезен намаз укыйм, кичен аның янына чабаммы?» – диде. Аңа янә: «Син, абый, намаз укый башла әле. Намаз укымауның гөнаһысы зина кылудан зуррак. Биш намазыңны укый башлагач та, килерсең миңа. Бергәләшеп сөяркәңнең өенә барырбыз да шыпырт кына сезгә никах укырмын», – дидем. Ул өмет белән китеп барды. Абый намазларда еш күренә башлады. Өч-дүрт айлап вакыт үткәч, аңа үзем килдем һәм: «Кайчан никах укытабыз инде?» – дип сорыйм. Ул миңа, елмаеп: «Минем аның янына барганым юк, хәзрәт», – диде. Намаз кешенең күңелен төзәтә, төзек күңел яман эшкә тартылмый. Намаз укудан куркырга кирәкми. Кайбер хатын-кызлар: «Мин намазымны укыр идем, әмма яулык ябынып йөри алмыйм», – диләр. Намаз укымауның гөнаһы яулыксыз йөрүгә караганда йөз, бәлки мең тапкырга күбрәк. Намаз вакыты кергән икән, яулыгыңны яп, күлмәгеңне ки дә намазыңны укы. Намазың ихлас булса, яулыгын да бәйләрсең, инша Аллаһ. Аллаһы Тәгалә беренче адымны бездән көтә, икенчесен безгә таба Үзе ясый. Раббысына якынаю юлын эзләүчене Ул Үзе якынайта.

Дилбәр Гарифуллина
(“Шәһри Казан”).

Нәшире
Иршат Гыйльметдин улы
ШӘЙХАТҖАР

Баш мөхәррир
Айгөл Абдуллина
Тел.: (8552) 70-51-09
Факс: (8552) 70-51-45

* * *

Оештыручылары:
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.

Электрон хатлар өчен:
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

Тиражы 1280.

Индексы 54149

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!
Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, таныш-ларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72

Басарга кул куелды:
график буенча
22 октябрь 16 сәг.
фактта 22 октябрь16 сәг.

Бәясе ирекле